**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

17 08 2026 ел Яр Чаллы ш. №2799

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 7/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлегендә, бинада яки башка күчемсез мөлкәттә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү турында шартнамә төзү хокукына сатулар (аукцион яки конкурс формасында) үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 4 июнендәге 693 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 7/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 кушымтаның 1 бүлеге 1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге кагыйдәләр дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлегендә, бинада яки башка күчемсез мөлкәттә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына сатулар (алга таба - шартнамә, сатулар) үткәрү тәртибен билгели, алар электрон формада үткәрелә һәм катнашучылар составы һәм тәкъдимнәр бирү рәвеше буенча ачык була.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү мәсьәләләре буенча урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов